РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАМАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423643, РТ, Менделеевский район, с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 , РТ, Менделеевск районы, Камай авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

2026 елның 04 февраленнән № 21

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районының «Камай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын
биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары,
мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре
турында, шулай ук хатынының (иренең)
һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре,
чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы
йөкләмәләре турында дөрес яисә тулы булмаган
белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны
бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары
куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлеше , «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылар, муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре,

чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибен расларга. (Кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районы рәсми сайтының http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Камай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Камай авыл җирлеге Советы рәисе И.М.Ахунҗанов

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районының Камай авыл җирлеге
Советының 2026 елның 04 февралендәге
21 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе.

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка карата (алга таба – муниципаль берәмлек) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешендә каралган җаваплылык чараларын карар кабул итүне регламентлый (алга таба — Тәртип).

2. муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка карата (алга таба – муниципаль берәмлек) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) муниципаль вазыйфаны биләүче затны, вәкаләтләре чоры туктатылганчы, тиешле җирле үзидарә органындагы вазыйфасыннан мәхрүм итеп, азат итү;

3) вәкаләтләре чоры туктатылганчы вәкаләтләрне даими нигездә башкару хокукыннан мәхрүм итеп, вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү; 4) җирле үзидарәнең тиешле органындагы вазыйфаларны аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы биләүне тыю;

5) вәкаләтләрне үз вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә башкаруны тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мәсьәлә Камай авыл җирлеге Советы (алга таба – Совет) тарафыннан карала. Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) советка кергән гаризасы тора.

4. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы Совет тарафыннан әлеге гариза әлеге органга кергән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча карала. Җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итәргә вәкаләтле Совет эшенең төп рәвеше сессияләр булса һәм Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы сессияләр арасындагы чорда кергән очракта, күрсәтелгән гариза ул кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка,аңа карата җаваплылык чаралары куллану турындагы мәсьәләне карау хакында, күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр кимендә биш эш көне кала язма рәвештә хәбәр итә. Муниципаль вазыйфаны биләүче затның урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән Совет утырышына килмәве, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карарга комачауламый

6. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы Совет утырышында карала. Күрсәтелгән мәсьәлә каралганда муниципаль вазыйфаны биләүче затка тапшырылган белешмәләр буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

7. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) гаризасын карау нәтиҗәләре буенча җаваплылык чарасын куллану турында, я җаваплылык чарасын куллануудан баш тарту турында Карар кабул ителә. Аңа карата Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) гаризасы кергән Депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. . Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар гаделлек, тигезлек, пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә, кылынган коррупциячел хокук бозуның характерын, аның авырлыгын, ул башкарылган шартларны исәпкә алып, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче затның үз вазыйфаи бурычларын

(вәкаләтләрен) үтәвенең алдагы нәтиҗәләрен, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәвен исәпкә алып кабул ителә. Хисап чорында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында бары тик бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозуга күрсәтмә, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерү хокукы булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезләмәсе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану турындагы яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре , ул кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфаны биләүче затка кул куеп тапшырыла , я тапшыру турында хәбәр белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) җибәрелә. Әгәр җаваплылык чарасын куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаса яисә күрсәтелгән зат имза салып карарны кабул итүдән баш тартса, Совет рәисе вазыйфаны биләүче затның җаваплылык чарасын куллану турындагы карар белән танышудан баш тартуы , яисә аңа хәбәр итү мөмкин булмау хакында акт төзи.

12. Җаваплылык чарасын куллану яки җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә шикаять ителергә мөмкин.